ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАБАР ЧЕРКЕНЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

КАРАРЫ

1 февраль 2019 ел №4

Табар Черкене авыл җирлегендә җирләү хезмәтләрен күрсәтү буенча гарантияләнгән исемлеклеккә кергән хезмәтләрнең бәяләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль закон, «Татарстан Республикасында Күмү һәм җирләү эше турында Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 24 гыйнварындагы 32 номерлы карары нигезендзә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Табар Черкене авыл җирлеге башкарма комитеты:

1. 2019 елның 1 февраленнән башлап Табар Черкене авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен әлеге карарның 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, авыл җирлегенең максус мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җирлек башлыгы Р.Х.Ибатуллин

2019 елның 1 февралендагы 4 номерлы
Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы Табар Черкене авыл җирлеге
Башкарма комитетының карарына
1 Кушымта

2019 елның 1 феврaленнән Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Табар Черкене авыл җирлегендә җирләү хезмәтләрен күрсәтү буенча гарантияләнгән исемлеклеккә кергән хезмәтләрнең бәяләре

| Хезмәтнең исеме | Бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2.Табутны һәм җирләү өчен кирәк башка әйберләрне бирү һәм китерү | 2211,17 |
| 3.Мәетне зиратка илтү | 919,2 |
| 4.Җирләү (кабер казу, күмү) | 2816,1 |
| Барлыгы | 5946,47 |

2019 елның 1 февралендагы 4 номерлы
Татарстан Республикасы
Апас муниципаль районы Табар Черкене авыл җирлеге
Башкарма комитетының карарына
2 Кушымта

2019 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Табар Черкене авыл җирлегендә җирләү хезмәтләрен күрсәтү буенча гарантияләнгән исемлеклеккә кергән хезмәтләрнең бәяләре

| Хезмәтнең исеме | Бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәк булган документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне киендерү | 1929,55 |
| 3. Табутны һәм җирләү өчен кирәк башка әйберләрне бирү һәм китерү | 594,52 |
| 4. Мәетне зиратка илтү | 867 |
| 5. Җирләү (кабер казу, күмү) | 2555,4 |
| Барлыгы | 5946,47 |